РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

20.08.2016 г. с.Соболевское № 16

Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 01 апрелендәге 6 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О. Н. Майорова

Югары Ослан муниципаль
районының Соболевский авыл
җирлеге башкарма комитетының
2016 елның 20 августында № 16
карарына
1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре исемлеге

| № т/б | Дәүләт хезмәтенең аталышы |
|---|---|
| 1. | Тууны дәүләт теркәве. |
| 2. | Никахлашуны дәүләт теркәвенә алу. |
| 3. | Никахны өзүне дәүләт теркәвенә алу. |
| 4. | Ата булуны билгеләүне дәүләт теркәве. |
| 5. | Үлемне дәүләт теркәве. |

Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге

| № т/б | Муниципаль хезмәт исеме |
|---|---|
| 1. | Күчемсез милек объектын бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару. |
| 2. | Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү. |
| 3. | Кадастр исәбенә кую максатында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен килештерү. |
| 4. | Җир кишәрлегенә белешмә, йорт биләмәсенә белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтәләр бирү. |
| 5. | Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау |
| 6. | Җир кишәрлеген сайлау актын килештерү. |
| 7. | Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү |
| 8. | Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү |
| 9. | Васыятьнамәләрне һәм ышанычнамәләрне таныклау |

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О. Н. Майорова